A. T. S. S. Ç. Qazan LENIN isem.
ƏLKƏ MASSA KITAPXANƏSE TƏP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
72. Х. № 27

ШИМБӘ
9 МАРТ
1940 ел
№ 56 (5856)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, тәнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ЛЕНИННЕҢ ҺӘМ СТАЛИННЫҢ ТУРЫЛЫКЛЫ КӨРӘШТӘШЕНӘ—СОВЕТ ХӨКҮМӘТЕ БАШЛЫГЫ ИПТӘШ МОЛОТОВКА БОЛЬШЕВИСТИК СӘЛАМ!

Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәше Вячеслав Михайлович Молотовка

Большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты сине, Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәшен, Совет хөкүмәте җитәкчесен—синең илле еллыгың көнендә кайнар рәвештә котлый.

Бөтен аңлы тормышың буена син большевиклар партиясенең күренекле эшлеклесе һәм юлбашчысы сыйфатында эшчеләр сыйнфы эшенә, коммунизм эшенә хезмәт итәсең. 1905—1907 нче еллардагы революция җиңелгәннән соң кара реакция елларында, эшчеләр хәрәкәтенең күтәрелеше елларында, „Звезда“ һәм „Правда“ чорында, бөтен дөнья күләмендәге беренче империалистик сугыш утында—син һәр вакыт большевизм байрагын югары тоттың, илебездә пролетариат диктатурасы өчен армый-талмый көрәштең.

Петроград Хәрби-Революцион Комитет члены буларак, син 1917 нче елның октябрендә зур революцион-большевистик эш алып бардың. Донбасснын, Украинаның, Москваның партия оешмалары җитәкчесе сыйфатында, ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре сыйфатында эшләвең белән, Совет хөкүмәте башлыгы постында озак еллык данлыклы эшең белән син партиянең һәм Советлар Союзы хезмәт ияләренең кайнар мәхәббәтен һәм гаять зур ихтирамын казандың.

Большевиклар партиясенең күренекле юлбашчыларыннан берсе буларак, социалистик экономиканы һәм яңа, коммунистик культураны гаять зур оештыручы буларак, син үзеңдә Ленин—Сталин тибындагы политик эшлекленең иң яхшы сыйфатларын гәүдәләндердең. Син марксизм-ленинизм идеяләре өчен һәр вакыт эзлекле көрәш алып бардың һәм алып барасың, партиянең һәм совет халкының дошманнарына каршы, троцкичыларга, зиновьевчыларга, бухаринчыларга һәм буржуазиянең башка агентларына каршы партиянең юлын тайпылышсыз саклаын.

Социализм иле үзенең уңышлары һәм җиңүләре өчен күп яктан синең энергияңә, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе постында синең армый-талмый эшләвеңә бурычлы. Партия һәм ил алдында телдән һәм матбугатта ясаган чыгышларыңда син коммунистик җәмгыять төзү буенча бөек эшнең гаять зур тәҗрибәсен туплыйсың.

Сиңа, кадерле дустыбыз һәм иптәшебез, чын күңелдән озак еллар буена сәламәтлек һәм партиябез файдасына, Ватаныбыз файдасына, коммунизм файдасына киләчәктә дә нәтиҗәле эш телибез.

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты.

Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәшенә, Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович Молотовка

Сезнең 50 еллыгыгыз көнендә ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Сезгә большевистик сәлам җибәрә һәм озак-озак еллар таза, сау-сәламәт яшәвегезне чын күңелдән тели.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Сезне, Ленин—Сталинның турылыклы көрәштәшен, дошманнарга карата большевикларча килешмәүчәнлекне үз халкы, үзенең партиясе эшенә чын күңелдән тирәнтен бирелгәнлек белән бергә алып баручыны, Ленин—Сталин типындагы эшлеклене котлый.

Үзегезнең бөтен аңлы тормышыгыз буенча яшь вакыттан ук Сез эшчеләр сыйныфын азат итү һәм социализм тантанасы эшенә багышладыгыз. Царизм вактында ук инде, Ленин партиясе байрагын югары тотып Сез царизмны бәреп төшерү өчен, революциянең җиңүе өчен армый-талмый көрәштегез. Партиябезнең тарихы буенча революциягә кадәр дә, шулай ук, пролетариат диктатурасы җиңгәннән соң да Сез күренекле эш алып бардыгыз. Петроград Хәрби-Революцион Комитеты члены сыйфатында Сез Октябрь революциясе көннәрендә Совет властеның тантанасы өчен көрәштегез. Социалистик революциянең бөтен еллары буена партия һәм совет җитәкчесе сыйфатында, ленинизмның җиңүе өчен, коммунизм дошманнарын юк итү өчен көрәшнең барлык этапларында Сез Ленин—Сталин партиясенең сугышчан байрагын бөтен принципиаль эзлеклелек белән йөрттегез.

Сезнең 50 еллыгыгыз ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе постында Сезнең тора башлавыгызның 10 еллыгы белән, бөек Ватаныбызның эчке тормышындагы һәм шулай ук халыкара мөнәсәбәтләрдәге гүзәл вакыйгаләргә тулы булган 10 еллык белән туры килә.

Бу 10 ел эчендә Советлар иле безнең бөек Сталин җитәкчелегендә социализм өчен көрәшнең барлык тармакларында гүзәл җиңүләргә иреште. Бу еллар эчендә СССР да социализмның бөек принциплары тантана иттеләр һәм тормышка ашырылдылар. Шушы елларның бөтенесе буена Сез СССР да социализм төзү эшендә, Совет социалистик хуҗалыгын, яңа социалистик җәмгыятне, эшчеләрнең һәм крестьяннарның яңа социалистик дәүләтен оештыру эшендә иптәш Сталинның иң якын ярдәмчесе булдыгыз һәм булып каласыз.

Совет хөкүмәте башлыгы постында үзегезнең көндәлек дәүләт эшегездә Сез партия күрсәтмәләрен һәм директиваларын тормышка ашыру үрнәге күрсәтәсез, дәүләт аппаратының җитәкчеләрендә һәм барлык работникларында Ленин—Сталин эшенә тирәнтен бирелгәнлек, җаваплылык хисе һәм эштә үзенең партия һәм дәүләт бурычын аңлау тәрбиялисез.

Халык хуҗалыгын оештыру буенча, бишьеллык планнарны эшләү һәм тормышка ашыру буенча, социалистик культураны күтәрү буенча үзегезнең эшегездә Сез һәр вакыт һәм һәр кайчан бу мәсьәләләрне большевикларча, Сталинча ничек хәл итәргә кирәклекне күрсәтәсез һәм шуңа өйрәтәсез.

Партиянең һәм дәүләтнең күренекле эшлеклесе буларак, Сез Совет дәүләтен ныгытуда армый-талмый эшлисез, Совет дәүләте аппаратын таркатырга һәм җимерергә маташкан дошманнарның маташуларын тайпылышсыз фаш итәсез.

Совет экономикасының һәм культурасының күренекле оештыручысы буларак, Сез үзегезнең бөтен көчегезне Советлар Союзының хуҗалык куәтен ныгытуга, Ватаныбыздагы хезмәт ияләренең культура һәм материаль хәлен күтәрү эшенә, Ватаныбыздагы барлык халыкларны Совет власте һәм Ленин—Сталин партиясе тирәсенә туплауга бирәсез.

Совет хөкүмәтенең башлыгы һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары сыйфатында Сез Совет дәүләтенең Ленинче—Сталинчы тышкы политикасын турылыклы һәм эзлекле үткәрүче булып торасыз, халыкара мөнәсәбәтләрдә тынычлык эшенең тантанасы өчен көрәшәсез һәм дәүләтебезнең оборона сәләтен, безнең җиңелмәслек Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең куәтен һәм данын ныгыту турында өзлексез кайгыртучанлык күрсәтәсез.

Сезнең йөзегездә без Совет хөкүмәте башлыгын, бөек остазыбыз һәм юлбашчыбыз иптәш **Сталинның** дустын һәм ярдәмчесен котлыйбыз.

Яшәсен бөек **Ленин—Сталин** партиясе!

Яшәсен социалистик дәүләтнең юлбашчысы—бөек Сталин!

Яшәсен Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович **Молотов!**

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы.

Иптәш Молотовка

Кадерле Вячеслав Михайлович!

Сезнең 50 еллыгыгыз көнендә ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты пленумы Сезгә, бөек Сталинның якын көрәштәше һәм дустына, Совет хөкүмәтенең сөекле җитәкчесенә үзенең большевикларча ялкынлы сәламен җибәрә!

Пролетар революция эшенә, эшчеләр сыйнфы эшенә, барлык хезмәт ияләре эшенә Сез күп еллар буена чын күңелдән хезмәт итеп киләсез. Сезнең тормышыгыз большевистик партиябез тарихы белән, хезмәт ияләрен эксплоататорлар изүеннән азат итү өчен көрәш белән аерылгысыз булып бәйләнгән. Сез—партиябезнең һәм халкыбызның иң яхшы улларыннан берсе.

Сез—партия өчен, пролетариат диктатурасы өчен, коммунизм өчен көрәштә иптәш Сталинның турылыклы көрәштәше. Партия Сезгә эшнең иң җаваплы тармакларын тапшырды һәм Сез, Вячеслав Михайлович, партиянең һәм халыкның дошманнарын рәхимсез тар-мар итеп, Ленин—Сталин тагълиматын ныклык белән һәм эзлекле рәвештә һәр җирдә дә тормышка ашырдыгыз, җиңүне тәэминиттегез.

Илебезнең бөек Сталин җитәкчелегендә ирешелгән тарихи уңышлары Сезнең исем белән, иптәш Молотов, турыдан-туры бәйләнгән. Совет дәүләтен төзүдә һәм ныгытуда, Сталинчыл тышкы политиканы тормышка үткәрүдә партия һәм халык алдында Сезнең хезмәтләрегез аеруча зур. Сезнең җитәкчелегегездәге Совет хөкүмәте—дөньядагы барлык хөкүмәтләрнең иң ныгы һәм авторитетлысы.

Без, Татарстан большевиклары, Сезнең, иптәш Молотов, Казанда большевиклар оешмасын төзүдә турыдан-туры катнашканлыгыгыз белән, революциягә кадәрге иң кыен чорда Казан большевикларының эшенә җитәкчелек иткәнлегегез белән горурланабыз.

Сезгә, Вячеслав Михайлович, хезмәт ияләре файдасына озак һәм озак еллар яшәүне һәм нәтиҗәле эшләүне телибез.

Яшәсен туганыбыз Совет хөкүмәте һәм аның җитәкчесе Вячеслав Михайлович Молотов!

Яшәсен бөек Сталин!

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш Вячеслав Михайлович Молотовны Ленин ордены белән бүләкләү турында

Большевиклар партиясен оештыру, Совет дәүләтен төзү һәм ныгыту эшендәге күренекле хезмәтләре өчен СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш Вячеслав Михайлович **Молотовны,** аның 50 еллыгы көнендә,—**Ленин ордены** белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
8 март, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Пермь шәһәренең исмен Молотов шәһәре дип һәм Пермь өлкәсенең исмен Молотов өлкәсе дип алмаштыру турында

Пермь шәһәренең һәм Пермь өлкәсенең җәмагат оешмаларының теләкләрен искә алып, Пермь шәһәренең исмен Молотов шәһәре дип һәм Пермь өлкәсенең исмен Молотов өлкәсе дип алмаштырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
8 март, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

7 нче мартта фронтта аеруча бер нәрсә дә булмады. Төньякта безнең частьләр Петсамо шәһәреннән 153 километр көньякта **Наутси** шәһәрен, Ладога күленең төньяк ярында, **Питкеранта** шәһәреннән көнбатышта **Максиман-саари, Петеясаари, Паймион-саари** һәм **Хонкасаари** атауларын алдылар.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә актив хәрәкәтләр алып барды. Шул вакытта дошманның 15 самолеты бәреп төшерелде.

***

8 нче мартта фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Выборг заливында безнең частьләр **Еси-Саари** атавын һәм **Есисаари** местечкосын, **Катилан-Саари** атавын һәм **Рахкасаари** местечкосын, **Терва-Саари** атавын, **Муста-Саари** атавын, **Хиета-Саари** атавын һәм местечкосын алдылар.

Безнең частьләр 12 орудие, 57 пулемет һәм 2 миллион патрон кулга төшерделәр.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә актив хәрәкәтләр алып барды һәм шул вакытта дошманның 2 самолеты бәреп төшерелде.

ВЯЧЕСЛАВ МИХАЙЛОВИЧ МОЛОТОВКА

КАДЕРЛЕ ИПТӘШ МОЛОТОВ!

Сезнең 50 еллыгыгыз көнендә РСФСР Верховный Советы Президиумы, Россия Совет Федератив Социалистик Республиканың барлык эшчеләре, колхозчылары һәм интеллигенциясе белән берлектә, Сезгә, большевиклар партиясен оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсенә, революциянең бөек юлбашчылары Лениннең һәм Сталинның турылыклы шәкертенә һәм көрәштәшенә, дөньядагы беренче социалистик дәүләт хөкүмәтенең башлыгына,—большевикларча ялкынлы сәлам җибәрә!

Бөек совет халкы һәм бөтен дөнья хезмәт ияләре Сезне нәтиҗәле эшегез һәм Ленин—Сталин эше өчен килешмәүчән көрәшегез өчен яраталар. Сезнең җитәкчелегегездә илебезнең хезмәт ияләре, Сталинчыл бишьеллык планнарны һәм Сталин Конституциясенең бөек идеяләрен тормышка ашырып, Ватаныбызны куәтле социалистик держава итеп әвереледерделәр.

Чит Ил Эшләре Халык Комиссары постында буларак, партиябезнең зирәк политикасын һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләрен гадәттән тыш осталык белән үткәреп, Сез Ватаныбызны яңа уңышларга ирештердегез. Социалистик дәүләтнең халыкара авторитеты һәм куәте көннән-көн үсә.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе постында Сез большевиклар партиясенең тышкы һәм эчке политикасын,—СССР ның коммунизмның тулы җиңүенә баручы 183 миллионлы халкына тыныч хезмәт тәэмин итүче политиканы иң яхшы үткәрүче булып торасыз.

Сезнең бөтен тормышыгыз—Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгәнлек үрнәге.

Сезгә, кадерле Вячеслав Михайлович, бөек социалистик Ватаныбыз файдасына һәм аның чәчәк атуы өчен күп еллар буена сәламәтлек һәм нәтиҗәле эш телибез.

РСФСР Верховный Советы Президиумы.

ВКП(б) ның Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе делегатлары игътибарына

Партиянең Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе шушы елның 10 нчы мартында, 18 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта ачыла. (Казан, Карл Маркс урамы, 26).

Делегатларны теркәү һәм делегатлык билетлары бирү 9 нчы мартта 9 сәгатьтән 23 сәгатькә кадәр һәм 10 нчы мартта 9 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бинасында, 35 нче бүлмәдә булачак (Казан, Б. Красный урам, 38). Оештыру комиссиясенең телефоннары: 26—80, 13—30, яки Өлкә Комитеты коммутаторы аркылы—10.

Оештыру комиссиясе.

ВЯЧЕСЛАВ МИХАЙЛОВИЧ МОЛОТОВ

КЫСКАЧА БИОГРАФИЯ

Вячеслав Михайлович Молотов (Скрябин) 1890 нчы елның 9 нчы мартында Вятка губернасының Кукарка бистәсендә (хәзерге Киров өлкәсе, Советск шәһәре) хезмәткәр семьясендә туган.

1902 нче елны Молотов Казандагы 1 нче реальный училищегә керә. 1905 нче елны ук инде ул революцион хәрәкәткә кушыла, царизмга каршы түгәрәкләрдә, митингларда һәм демонстрацияләрдә катнаша. 1906 нчы елны Молотов Казан шәһәрендә социал-демократлар (большевиклар) оешмасына керә. Ул укучы яшьләрнең революцион настроениедәге өлешен төп оештыручыларның берсе була. Укучыларның революцион оешмасы үзенең бөтен шәһәр күләмендә житәкче үзәген төзи һәм бу үзәккә Молотов та керә.

„1908—1912 нче еллар революцион эш өчен иң кыен чор булды. Революция жиңелгәннән соң, революцион хәрәкәтнең төшенкелеге һәм массаларның арганлыгы шартларында большевиклар үзләренең тактикасын үзгәрттеләр һәм царизмга каршы турыдан-туры көрәштән бу көрәшнең әйләнешле юлларына күчтеләр“. („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, бит 163). Реакция чорындагы авыр шартларда иптәш Молотов революцион көчләрне жыю өчен, патша самодержавиесенә каршы яңа һөҗүм хәзерләү өчен иң кечкенә легаль мөмкинлекләрдән дә файдалана.

Укучыларның революцион оешмасы (үзенең житәкчеләреннән берсе иптәш Молотов булган оешма) Казандагы уку йортларында яшрен марксистик түгәрәкләр төзи, мәктәптәге казарма режимына каршы укучыларның оппозицион чыгышларына житәкчелек итә, төрмәләргә ябылган һәм сөргенгә жибәрелгән революционерларга акча жыюны һәм материаль ярдәм оештыра, большевистик әдәбият таратуда ярдәм итә, эшчеләр арасында пропаганда эше алып бара.

1909 нчы елның апрелендә Молотов укучыларның революцион оешмасының башка күп кенә членнары белән берлектә кулга алына һәм шул ук елның июнендә ике елга Вологда губернасына: башта Тотьмага һәм Сольвычегодскига, ә аннары Вологдага сөргенгә жибәрелә. Монда ул экстерн тәртибендә реальный училищегә имтихан тапшыра.

Вологдада полиция күзәтүе астында торганда Молотов шәһәрдә төп пролетар кадрлар булган тимер юл эшчеләре арасында актив рәвештә яшрен партия эше алып бара. Иптәш Молотов яшрен революцион партияне бетерүне, нинди булса да яшрен эш алып баруны бетерүне таләп итүче меньшевикларга каршы чыга. Ленин һәм Сталин житәкчелегендә большевиклар буржуазиянең иуда—Троцкий канаты астындагы лакейларына каршы рәхимсез көрәш алып баралар. Вологда шәһәрендә Молотов төзегән большевиклар оешмасы 1910—1911 нче елларда үзенең эшен көчәйтә һәм Ленин юлын нык үткәрә.

Ул елларда Молотов марксизм классиклары әсәрләрен өйрәнүгә зур игтибар бирә. Вологданың һәм Вятканың жандарм идарәләре үзләренең агентлык сводкаларында Молотов „социал-демократларның программасын һәм әдәбиятын бик яхшы белүе белән аерыла“, „жидди оештыручы булып санала“ дип күрсәтәләр.

Сөргендә булу срогын тутырганнан соң 1911 нче елның июнендә Молотов Петербургка бара һәм Петербургдагы политехника институтына керә. Монда ул студентлар арасында большевистик группалар туплау буенча зур эш алып бара. Аның актив катнашы белән Петербургның башка югары уку йортларында да большевистик группалар төзелә һәм алар большевистик студентлар оешмаларының гомуми шәһәр комитетына берләшәләр. Петербургның большевистик студентлар оешмалары күп кенә яшрен түгәрәкләр төзиләр, студентларның царизмга каршы революцион чыгышларына житәкчелек итәләр, большевистик прокламацияләр тараталар һ. б. Большевистик студентлар оешмалары партиягә белемле пропагандистлар кадрлары бирәләр. Молотов эшчеләрнең берничә түгәрәгендә эшли.

1912 нче ел башыннан алып иптәш Молотов большевистик „Звезда“ газетасында эшли. Ә аннары үзенең оешмаларын ныгыту һәм масса арасында йогынты яулап алу эшендә большевистик партиянең кулында куәтле корал булган көндәлек большевистик „Правда“ газетасын төзүдә якыннан торып катнаша. Молотов „Правда“ редакциясе составына керә һәм анда актив катнаша, үзенең мәкаләләрен имзасыз яки А. Рябин, В. Михайлов, А. Званов фамилияләре кебек төрле яшрен фамилияләр белән яза. Шул вакыттан алып Молотов „Правда“да иптәш Сталин белән очраша башлый. 1912 нче елны редакциянең секретаре һәм „Правда“ житәкчеләренең берсе буларак Молотов большевикларның чит илдәге үзәге һәм В. И. Лениннең үзе белән хатлар язышa. Полициянең эзәрлекләве аркасында ул 1912 нче елның ахрында яшрен хәлгә күчәргә мәжбүр була. Шундый эзәрлекләүләргә дә карамастан, Молотов зур эш алып бара. Ул—большевикларның Петербург комитеты члены, Выборг районында һәм Николаев (хәзерге Октябрь) тимер юлы эшчеләре арасында пропаганда эше алып бара һәм IV нче дәүләт думасына сайлау кампаниясендә житәкче сыйфатында катнаша һәм либераль буржуазия белән килешү тарафдарларының—меньшевикларның хыянәтчел позициясен фаш итә. Молотов думаның большевиклар фракциясенә житәкчелек итүдә дә катнаша.

1913 нче елның апрелендә „Студентларның берләштерелгән социал-демократик комитеты“н патша охранкасы бетергән вакытта Молотов кулга алына һәм берничә айдан соң Петербургдан сөрелә. Аның күп кенә зур шәһәрләрдә һәм промышленность губерналарында торуы тыела („64 пункт“ дигән нәрсә).

Төрмәдән чыкканнан соң Молотов Петербургка якын гына урында урнашып, большевикларның Петербург оешмасында һәм „Правда“да яшрен рәвештә партия эшен дәвам иттерә.

Шул ук чорда Молотов Петербург профсоюзларының эшендә актив катнаша, эшчеләрнең профсоюз жыелышларында речьләр сөйли, аларның эшен „Правда“да яктырта, профсоюзлардагы большевик работникларга, шулай ук профсоюз журналлары чыгаруда ярдәм итә. Профессиональ союзларның күпчелеген большевиклар ягына яулап алу турында Ленин—Сталин директиваларын тормышка ашыру өчен Молотов чиксез энергия белән көрәшә. Маглүм ки, яшрен эшне легаль эш белән бергә кушып, большевиклар бу бурычны үти алдылар һәм профсоюзларның житәкче органнарына сайлауларда күп кенә гүзәл уңышларга ирештеләр.

1913 нче елның ахрында РСДРП(б)ныңПетербург Комитеты эшендә катнашуы өчен Молотов яңадан кулга алына, ләкин дәлилләре житәрлек булмаганлыктан азат ителә һәм полиция күзәтүе астында калдырыла. Петербургның үзендә тору тыелганлыктан Молотов яңадан Петербург тирәсенә күчә һәм эшчеләр арасында революцион эшен дәвам иттерә, „Правда“да һәм большевикларның икенче бер органында—„Просвещение“ журналында язышa.

1914 нче елның маенда Молотовны яңадан кулга алалар һәм озак та үтми сөргенгә жибәрәләр. Аңа башкалада һәм күп кенә башка шәһәрләрдә һәм губерналарда тору тыела („45 пункт“ дип аталган нәрсә).

Империалистик сугыш башланганда Молотов Петербургда була. Сугыш турындагы мәсьәләдә ул эзлекле ленинчел позициядә тора. Ул бу сугышның империалисик талаучылык характерын фаш итә, эшчеләр оешмалары сафларындагы шовинистик настроениеләргә каршы килешмәүчән көрәш алып бара.

Озакламый Молотов Москвага күчә һәм анда сугыш башланганда патша охранкасы тарафыннан таратылган большевистик оешманы аякка бастыру эшен жәелдерә. Ул Москва большевикларының таркау көчләрен жентекләп жыя һәм партия сафларын күп санлы провокатор-охранниклардан чистарта: ул Москваның төрле районнарында берничә актив большевистик группалар оештыруга ирешә. Молотов төп эшен Лефортово, Симоново һәм Пресня районнары эшчеләре арасында алып бара, Москвадагы заводларда һәм фабрикаларда партия оешмалары төзүгә житәкчелек итә, царизмга һәм империалистик сугышка каршы большевистик әдәбият чыгару һәм аны тарату эшенә житәкчелек итә.

1915 нче елның язында Москва большевикларының гомуми шәһәр конференциясен чакыру хәзерләнелә, ләкин оешмага үтеп кергән провокаторлар доносы буенча Молотов июнь аенда кулга алына һәм шул ук елның сентябрендә этап тәртибенә Иркутск губернасына (Манзурка авылына) 3 елга сөргенгә жибәрелә.

1916 нчы елның маенда Молотов Себердән сөргеннән качып Петроградка кайта һәм анда яшрен эш алып бара. 1916 нчы елның көзендә Молотов большевиклар партиясенең чит илдәге Үзәк Комитеты күрсәтмәсе буенча большевиклар Үзәк Комитетының Россия бюросы составына кертелә һәм бу бюрога житәкчелек итә. Үзәк Комитетның иптәш Молотов житәкчелегендәге бюросы бу чорда большевиклар партиясенең практик эшенә житәкчелек итә. Большевиклар Үзәк Комитеты бюросы һәм Петербург комитеты тарафыннан сугышка һәм эшчеләр хәрәкәтенең көндәлек бурычларына багышлап чыгарылган күп кенә сугышчан прокламацияләр Молотовның якыннан торып катнашуы белән чыгарылалар. Бу чорда Молотов бердән-бер легаль большевистик журнал булган „Вопросы страхования“ журналында сотрудниклык итә. Бу журналның чыгуын иптәш Сталин зур вакыйга дип күрсәтеп үткән иде.

Молотов 1917 нче елгы Февраль революциясен хәзерләгән революцион хәрәкәткә большевистик житәкчелек итүгә турыдан-туры

Иптәш В. М. Молотовның политехника институтында укыган вакты. (Революция музее материалларыннан). ТАСС фотоклишесе.

катнаша. Февральдәге буржуаз-демократик революция вактында һәм аннары Петроградта шуннан соңгы бөтен эше дәвамында Молотов—РСДРП(б) ның Петроград комитеты члены. Большевиклар партиясенең вәкиле сыйфатында ул эшче депутатларның Петроград советының башкарма комитеты төзелгән көннән бирле аның составына керә, анда солдатлар секциясе төзүдә һәм Петроград советын эшче һәм солдат депутатлары советы итеп әверелдерүдә якыннан торып катнаша, советның большевистик фракциясе эшендә катнаша.

Молотов „Правда“ ны торгызу һәм чыгару эшенә житәкчелек итә һәм Сталин сөргеннән кайтканга кадәр „Правда“ның төп редакторларының берсе була. Молотов партиянең апрель конференциясенең, VI нчы съездының эшләрендә дә актив катнаша, Петроград большевиклары оешмасы житәкчеләренең берсе була.

Партиянең VI нчы съездында сөйләгән речендә Молотов, Ленингә һәм Сталинга ияреп, „властьны бары тик көч белән генә алырга мөмкин“ дип күрсәтә. „Властьны бары тик пролетариат һәм иң ярлы крестьяннәр генә үз кулларына алырга телиләр, үзләрен вәкил иткән күпчелек интересларында алар гына моны эшли алалар һәм эшләрләр“. Иптәш Молотов, безгә „хәзерге хәлдән бердәнбер котылу юлын—пролетариат һәм ярлы крестьяннәр диктатурасын эштә күрсәтергә кирәк“ диде.

Октябрь социалистик революциясен хәзерләү вактында һәм революция көннәрендә Молотов—Петроградта турыдан-туры Ленин һәм Сталин житәкчелегендә эшләүче большевиклар житәкчеләренең берсе. Большевикларның Петроград комитеты вәкиле сыйфатында ул октябрь көннәрендә восстаниегә житәкчелек иткән Хәрби-Революцион комитет составына керә. Бөек Октябрь Социалистик революциясе жиңгәннән соң Молотов эшче һәм солдат депутатларының Петроград советы житәкчеләренең берсе була.

1918 нче ел башында партия Молотовны Төньяк өлкәнең халык хуҗалыгы советы председателе итеп күтәрә. Ул вакытта бу өлкәгә төньяктагы 7 губерна, шул исәптән Петроград губернасы да керә иде. Аның житәкчелегендә Петроградта һәм бөтен Төньяк өлкәдә фабрикаларга һәм заводларга национализация үткәрелә, производствога эшчеләр контроле оештырыла. Шушы эш процессында Петроград заводларының эшчеләре производствоны идарә итүнең катлаулы техникасын үзләштерәләр һәм беренче тапкыр буларак үз араларыннан социалистик хуҗалыкны төзүче житәкче кадрлар күтәрәләр.

1919 нчы елның жәендә Молотов Волга буенда партиянең һәм Совет хөкүмәтенең уполномоченные итеп билгеләнә. Аңа чех-словак һәм колчак гаскәрләреннән азат ителгән районнарда иң кыска срок эчендә совет һәм партия оешмалары төзү һәм аларны ныгыту тапшырыла. Молотов төрле наркоматларның житәкче работниклары белән берлектә берничә ай эчендә Волга һәм Кама буйларындагы шәһәрләрдә (Нижний-Новгород, Чебоксар, Казан, Чистай, Ижевск, Пермь, Сембер, Самара, Саратов һ. б.), шулай ук Волга һәм Кама буендагы күп кенә авылларда була. Иптәш Молотов житәкчелегендә Волга буенда партия һәм совет аппараты ныгый.

1919 нчы елның ахрыннан башлап Молотов Нижний Новгород губерна башкарма комитеты председателе, ә 1920 нче елның сентябрендә аны партиянең Үзәк Комитеты Донбасска жибәрә. Монда ул Донбасс Губкомының секретаре итеп сайлана. РКП(б) ның IX нчы Бөтенроссия съездында Молотов РКП(б) Үзәк Комитеты членлыгына кандидат итеп сайлана. 1920 нче елның ноябрендә ул Украина КП(б) Үзәк Комитетының члены һәм секретаре итеп сайлана. 1920—21 нче елларда Молотов профсоюзлар дискуссиясендә барлык оппозицион агымнарга каршы—троцкичыларга һәм бухаринчыларга каршы, „эшчеләр оппозициясе“нә һәм децистларга („демократик централизм“ дип аталган группага) каршы Ленин юлын нык үткәрә.

Партиянең X нчы съездында, 1921 нче елның мартында, партия Ленин житәкчелегендә яңа экономик политикага күчкәч, Молотов РКП(б) Үзәк Комитетының секретаре итеп, шулай ук Үзәк Комитет Политбюросы членлыгына кандидат итеп сайлана. РКП(б) Үзәк Комитетында Молотовның бөтен эше Ленин һәм Сталин белән турыдан-туры көндәлек элемтә нигезендә, алар житәкчелегендә бара.

Шушы вакыттан башлап В. М. Молотов Москвада эшли. Ул партиянең һәм Совет дәүләтенең бөтен житәкче эшендә катнаша, партиянең троцкизмга һәм башка вак буржуаз группаларга һәм агымнарга каршы көрәшендә Ленин юлын тайпылышсыз яклый.

1926 нчы елның гыйнвареннан башлап, партиянең XIV нче съездыннан соң, Молотов ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы члены. 1927 нче елда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының члены итеп, ә 1929 нчы елны—СССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы члены итеп сайлана.

Партиянең төп юлы өчен, илебезне индустрияләштерү өчен көрәштә Молотов зур роль уйный. Партиягә каршы булган троцкичы-зиновьевчы блокның казынуларын фаш итеп, Молотов, оппозициянең иң характерлы ягы илебездә социализм төзү мөмкинлегенә аның ышанмавы дип күрсәтте. Империализмның троцкичы-зиновьевчы агентларының социалистик жәмгыят төзүне өзәргә, партиягә СССР ны империалистик дәүләтләрнең экономик коллыгына төшерү планын көчләп тагарга маташуларын ул рәхимсез рәвештә фаш итте.

Иптәш Сталин фикерен жәелдереп, Молотов социалистик промышленность алдына „авыл хуҗалыгын үстерүнең актив һәм чыннан да куәтле этәргече булып әверелү, өр яңа техника, коллектив хезмәт һәм эре производство нигезендә аны үзгәртеп кору өчен тагын да зуррак шартлар тудыру“ бурычын куя.

Иптәш Молотов, безнең бөтен тышкы һәм эчке хәлебез илне индустрияләштерүнең тизләтелгән темпын эзлекле төстә үткәрүне таләп итә диде. Бөтен халык хуҗалыгына башланган реконструкцияләүнең иң әһәмиятле шарты нак әнә шул икәнлекне иптәш Молотов аеруча күрсәтеп үтте.

Авыл хуҗалыгына социалистик реконструкция ясау эшендә иптәш Молотовның хезмәтләре бөтен илгә маглүм.

Партиянең уңнарга каршы кызу көрәше чорында, 1928 нче елның урталарында иптәш Молотов ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре булып эшләү белән бер рәттән, ВКП(б) ның Москва Комитеты секретаре итеп сайлана. Партиянең төп юлын яклап, иптәш Молотов троцкичы-бухаринчы кабахәтләргә жимергеч ударлар ясый. Ул шулай ук черек либерализмга һәм килешүчәнлеккә каршы да кискен төстә чыга.

1930 нчы елның 19 нчы декабреннән башлап В. М. Молотов—СССР Совнаркомы председателе постында.

1930 нчы елны Үзәк Комитетның һәм Үзәк Контроль Комиссиясенең берләштерелгән декабрь пленумында сөйләгән речендә, СССР Совнаркомы председателе итеп билгеләнүе уңае белән В. М. Молотов болай диде:

„Хәзер, яңа урынга билгеләнгәнлегемнән, мин үз турымда да, үземнең эшем турында да берничә сүз әйтми кала алмыйм. Мин большевиклар партиясендә үстем һәм аның белән күп еллык өзлексез эш аркылы бәйләнгәнмен. Коммунист буларак миндә эштә Лениннең шәкерте булудан башка теләк юк һәм була да алмый. Миңа турыдан-туры Ленин житәкчелегендә аз эшләргә туры килде, ләкин коммунист буларак минем өчен Маркс—Ленин таглиматын үзләштерү һәм марксизм-ленинизм таглиматын тормышка ашыру эшендә актив катнашу һәр вакыт төп бурыч булды һәм шулай булып кала. Соңгы еллар эчендә Үзәк Комитет секретаре сыйфатында миңа Лениннең иң яхшы шәкертенең турыдан-туры житәкчелегендә, иптәш Сталинның турыдан - туры житәкчелегендә большевистик эш мәктәбе үтәргә туры килде. Мин моның белән горурланам.

Моңа кадәр миңа башлыча партия работнигы сыйфатында эшләргә туры килде. Сезгә белдерәм, иптәшләр, Совнаркомда эшләүгә дә мин партия работнигы сыйфатында, партиянең һәм аның Үзәк Комитетының теләген үткәрүче сыйфатында киләм“.

Иптәш Молотовның турыдан-туры житәкчелегендә илебезне Сталинчыл индустрияләштерү Кызыл Армияне һәм Хәрби Диңгез Флотын техника белән бик яхшы итеп кораллландыруны тәэмин итте. Молотов Кызыл Армия һәм Флот кадрларына зур игтибар бирә. ССР Союзы Үзәк Башкарма Комитетының 1936 нчы елның гыйнварында булган II нче сессиясендә иптәш Молотов „бөтен армиябез чын күңелдән бирелгән һәм үз эшләрен ахрынача белүче сугышчылардан—очучылардан, артиллеристлардан, химиклардан, танкистлардан, укчылардан һәм башка төрле кирәкле корал төре сугышчыларыннан торсын“ дигән бурычны куйды һәм „армиябезнең житәкче кадрларын тагын да ныгыту һәм аларның әһәмиятен күтәрү“ кирәклеген аеруча күрсәтеп үтте.

1939 нчы елны Молотов элекке хезмәте өстенә СССР ның Чит Ил Эшләре Халык Комиссары итеп билгеләнә.

Гаять катлаулы халыкара обстановка шартларында, икенче империалистик сугыш бөтен дөнья сугышы булып үсеп бара торган шартларда Молотов Сталинчыл тынычлык политикасын тормышка ашыра һәм иптәш Сталин күрсәтмәләрен тормышка ашыру нигезендә СССР ның халыкара авторитетын ныгыту юлында зур уңышларга ирешә. Германия белән СССР арасында сәүдә-кредит килешүе, СССР белән Германия арасында һөҗүм итешмәү турындагы договор, дуслык һәм чик турындагы договор, Германия белән хуҗалык килешүе—СССР белән Германия арасында дуслык мөнәсәбәтләре тудырган шушы барлык тышкы политика актлары Советлар Союзын Англия—Франция империалистларының үз интересларын хакына сугышка тартырга маташуларының көлен күккә очырды. Латвия, Эстония һәм Литва белән үзара ярдәмләшү турында договорлар төзелде. Демократик Финляндиянең Халык Хөкүмәте белән үзара ярдәмләшү турында пакт төзелә һәм Ленинград якынында фин ак гвардеецлары тарафыннан тудырылган иң куркынычлы сугыш учагы шул пакт нигезендә бетерелә. Чит ил эшләре халык комиссары постында тора башлаганнан бирле кыска гына вакыт эчендә иптәш Молотов СССР ның тышкы политикасының тарихи әһәмияте булган күп кенә мәсьәләләрен хәл итә алды.

Молотовның речьләре, докладлары һәм мәкаләләре марксизм-ленинизм теориясен баеталар; алар үзләренең үткен очлары белән барлык һәм һәр төрле антиленинчел агымнарга һәм тайпылуларга каршы юнәлдерелгәннәр.

1921—1930 нчы еллар эчендә Молотов ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре сыйфатында партия төзелеше һәм партия кадрларын сайлап алу мәсьәләләре белән шөгыльләнде. Бу темаларга аның түбәндәге әсәрләре чыкты: „Партия практикасы мәсьәләләре“ (брошюра), „Партия һәм Ленин призывы“ (брошюра), оештыру мәсьәләләре буенча партиянең XI, XIII пәм XIV нче съездларында ясалган докладлар һ. б.

Коллективлашуны хәзерләү һәм аны үткәрү чорында Молотов партиянең авылдагы эшенә бәйле мәсьәләләр буенча партия съездларында, конференцияләрендә һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумнарында кулланма докладлар ясады. Бу темага безнең большевистик матбугатта аның күп кенә мәкаләләре чыкты. Бу мәсьәләләр буенча В. М. Молотовның хезмәтләреннән барыннан да элек түбәндәгеләрне күрсәтеп үтәргә кирәк: „Авылда партия политикасы“ исемендә мәкаләләр һәм речьләр жыентыгы, „Авылда эшләү турында“ партиянең XV нче съездында доклад.

Илне социалистик индустрияләштерү мәсьәләләре, беренче, икенче һәм өченче бишьеллыклар, совет төзелеше һәм Совет Конституциясе, милли мәсьәлә һәм СССР халыкларының дуслыгы һәм, ниһаять, халыкара политика мәсьәләләре—иптәш Молотовның мәкаләләрендә һәм речьләрендә бу темаларның барсына да зур игтибар бирелә. Иптәш Молотовның түбәндәге әсәрләре басылып чыкты: „Социализм өчен көрәштә“—мәкаләләр һәм докладлар жыентыгы, „СССР халыкларының бөек дуслыгы“—речьләр жыентыгы, „Мәкаләләр һәм речьләр“ (1935—1936 нчы еллар), „Октябрь революциясенең XX еллыгына карата“, „Октябрь революциясенең XXI еллыгы“, „Октябрь революциясенең XXII еллыгы“, „Югары мәктәп турында“ һәм СССР ның эчке һәм тышкы политикасы мәсьәләләре буенча күп кенә речьләр.

Бөтен совет халкы Вячеслав Михайловичның нәтиҗәле эшен тирән ихтирам һәм чиксез мәхәббәт белән билгеләп үтә. Иптәш Молотовка үзләренең мәхәббәтләрен СССР халыклары аны СССР Верховный Советына, Союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына бердәм рәвештә депутат итеп сайлауда күрсәттеләр. Советлар Союзы хезмәт ияләре ныклы Ленинче — Сталинчы Вячеслав Михайловичка 50 ел тулу уңае белән кайнар сәлам һәм котлау жибәрәләр.

Бөек Сталинның якын көрәштәше һәм дусты—Вячеслав Михайлович Молотов озак еллар яшәсен!

СОВЕТ ХӨКҮМӘТЕ БАШЛЫГЫ*)

А. ВЫШИНСКИЙ

Сталин һәм Молотов иптәшләр стахановчылар киңәшмәсендә (1935 нче ел). Н. Кулишов фотосы.

1937 нче елның 11 нче декабрендә сайлау алды җыелышында сөйләгән речендә иптәш Сталин болай диде:

„...халык үзләренең депутатларыннан шуны таләп итәргә тиешләр ки... алар Ленин типындагы политик эшлеклеләр постында калсыннар, алар Ленин кебек үк, кем икәнлекләре ачык булган һәм билгеле булган эшлеклеләр булсыннар, алар Ленин кебек үк, сугышта куркусыз һәм халык дошманнарына карата рәхимсез булсыннар, алар, эш кыенлаша башлаганда һәм горизонтта нинди дә булса куркыныч гәүдәләнгәндә һәр төрле паникадан, паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән азат булсыннар, алар, паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән, Ленин кебек үк, азат булсыннар, алар, һәр яклап ориентация алу һәм барлык плюсларны һәм минусларны һәр яклап исәпкә алу кирәк булган катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә, Ленин кебек үк, бөек акыллы һәм ашыкмаучан булсыннар, алар, Ленин кебек үк, турылыклы һәм намуслы булсыннар, алар үз халкын, Ленин яраткан кебек үк, ятратсыннар“.

Вячеслав Михайлович Молотов Ленин типындагы нак әнә шундый политик эшлекле. Халыкара пролетар хәрәкәт тарихына, дөньяда беренче социалистик дәүләт төзү өчен илебездәге эшчеләрнең һәм крестьяннарның көрәше тарихына кергән гаят әһәмиятле вакыйгалар иптәш Молотов исменә бәйләнгәннәр.

В. М. Молотов—Бөек Октябрь Социалистик революциясен оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе, Совет властен оештыручыларның берсе, Совет хөкүмәтенең күренекле җитәкчесе. Совет Социалистик Республикалар Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе постында алмашсыз рәвештә ун ел буе диярлек эшләп килә.

Иптәш Молотов бу постка 1930 нчы елны килде. Бу ел СССР да социалистик төзелеш тарихына соңгы ун еллыкның иң гүзәл елларыннан берсе булып керде. Ул Сталинчыл беренче бишьеллыкның өченче хәл иткеч елы иде.

1930—1940 нчы еллар эчендәге һәрбер ел бөтен дөнья тарихының нинди генә эпохасының да уннарча елына тора. Бу ун еллык СССР да социализмның җиңүе белән, бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмиятле акт белән—Бөек Сталин Конституциясе төзелү белән истә калдырылды; Ленин—Сталин партиясе тирәсенә тупланган, әлегә кадәр башка бер нинди илдә дә күрелмәгән һәм булуы мөмкин булмаган мораль һәм политик бердәмлекләрен бөтен дөньяга күрсәтүче Советлар Союзы халыкларының иҗад көчләре балкып чәчәк ату белән истә калдырылды.

Сталинның даһи җитәкчелеге бөтен халык хуҗалыгы фронтында капиталистик элементларга каршы кискен һөҗүмнең, 1929 нчы елны иптәш Сталин тарафыннан „бөек борылыш елы“ дип аталган елда башланган һөҗүмнең тулы уңышын тәэмин итте.

Бу җиңүнең әһәмияте гаят зур булды. Аның нәтиҗәләренә бәя биреп, В. М. Молотов 1929 нчы елны 1918 нче ел белән чагыштыра: 1918 нче елны „социалистик революция чын-чынлап шәһәрдән авылга атлады“, 1929 нчы елны крестьяннарның төп массасы—урта хәлләләр—социализмга таба тәмам борылдылар.

Крестьяннар массасын пролетариатның үз ягына яулап алуы социалистик революциянең уңышын хәл итте.

1918 нче елны да шулай булган иде, 1929 нчы елны да шулай булып чыкты.

„Бу ике этапның илебездә социализм эше өчен хәл иткеч әһәмияте бар. Бу ике дата—1918 һәм 1929 нчы еллар—хуҗалыкның иң артта калган һәм иң кыен фронтында—авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору фронтында социализм җиңүләренең маяклары“. (В. Молотов. „Социализм өчен көрәштә“, 218 нче бит).

Крестьяннарның төп массасының социализмга таба тәмам борылуы буржуаз контрреволюциянең СССР да капитализмны торгызуга булган барлык өметләренең бөтенләй җимерелүен күрсәтте.

Капиталистлар, беренче чиратта элек-электән үк советка каршы һөҗүмнәр һәм провокацияләр оештырып килгән Англия—Франция буржуазиясе, халыкара талаучылар һәм профессиональ сугыш уты кабызучылар, бөтен үткән еллар эчендә Совет дәүләтенә каршы системалы рәвештә ачыктан-ачык та, яшертен дә һәр төрле заговорлар оештыру белән шөгыльләнделәр. Моның өчен алар СССР да һәм чит илләрдә советка каршы булган һәр төрле группалардан файдаландылар.

Троцкичылар һәм уңнар, меньшевиклар һәм эсерлар, „Промпартия“ дип аталган нәрсәнең членнары, Чаяновның—Кондратьевның кулаклар группасы, шпионнар, диверсантлар һәм террорчылар халыкара буржуазиянең иң явыз өлешенең котыртуы буенча Советлар Союзына каршы, Совет властена каршы елдан-ел көрәшеп килделәр.

Халыкара юлбасарларның һәм аларның уң-троцкичы агентурасының бу мәкерле эшләрен партиябез фаш итте. Заговорчылар һәм хыянәтчеләр тар-мар ителделәр. Социализм дошманнарын тар-мар итү СССР да яңа җәмгыять строе оештыру өчен көрәшне җиңеләйтте.

Дошманнарны тар-мар итү һәм Совет дәүләтенең куәтен ныгыту буенча бу гигант эштә Совет хөкүмәтенең башлыгы һәм җитәкчесе, Ленин—Сталин типындагы күренекле политик һәм җәмагать эшлеклесе, партиябезнең күренекле теоретигы, ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро члены, бөек Сталинның якын көрәштәше В. М. Молотов күренекле урын тота.

* * *

СССР ның социалистик промышленностеның һәм беренче чиратта авыр индустриянең куәтле үсүенә нигез салган беренче бишьеллык еллары шәһәрдәге һәм авылдагы кулак—капиталист элементларның социалистик төзелешкә каршылык күрсәтергә маташулары аеруча көч белән җәелгән еллар булды.

1927—1928 нче елларда хуҗалыгыбызның үсешендә мәгълүм кыенлыклар булды. Алар гаят күп көч куюны таләп иткән яңа гигант бурычлар белән бәйләнгәннәр иде. Бу кыенлыклар илнең җитештерү көчләрен үстерүдәге, күтәрүдәге, алга җибәрүдәге кыенлыклар иде.

Уң һәм „сул“ куркынычларга каршы көрәшнең башында торган һәм уң, „сул“ хыянәтчеләрне тар-мар итүне оештырган иптәш Сталин җитәкчелегендә партия барлык кыенлыкларны җиңде.

Партиянең XV нче съезды чорында инде зур кискенлек белән җәелгән бу көрәштә капитулянтларны тар-мар итүдә иптәш Сталинның күренекле ярдәмчеләреннән берсе иптәш Молотов булды.

Партиянең XV нче съездында иптәш Молотов шәһәрдә дә, авылда да халык хуҗалыгының барлык тармакларында социалистик команда югарылыкларын киңәйтүне һәм ныгытуны тәэмин итәргә тиеш булган һәм чыннан да тәэмин иткән киң практик чаралар программасын бирде.

Авылда эшләү турында партиянең XV нче съездында иптәш Молотов ясаган доклад ул вакытта авылның хәлен характерлаучы экономик һәм политик фактларга ачык анализ бирде.

Безнең авылда урта хәлле крестьяннар массасының тоткан урны ничек үсүне иптәш Молотов ачык күрсәтте һәм авылның революциягә кадәрге хәле белән чагыштырганда, совет авылының үсешендә бу фактның принципиаль яңа факт булуын аеруча әйтте.

Оппозиция сафларындагы капитулянтларны фаш итеп, иптәш Молотов авылның алдагы үсү юллары турындагы сорауга үзенең докладында гадәттән тыш ачыклык белән тулы җавап бирде. Иптәш Молотов авылда социалистик элементларның ныгыганлыгын, аларның үсүен һәм тагын да зуррак уңыш белән үсәчәкләрен һәм безнең бурыч бу үсүгә барлык чаралар белән булышлык итүдән гыйбарәт икәнлекне күрсәтте.

Нак менә шул яктан карап, иптәш Молотов „безнең политиканың хәзерге чорының мәгънәсен“ авылның җитештерү көчләренең „капиталистик методлар“ ярдәме белән үсүендә күргән уң-троцкичы установкаларны җимергеч рәвештә тәнкыйтьләде. Крестьян хуҗалыгының җитештерү көчләре тиз үсүнең бердән-бер юлы—„Капиталистик методлар“ түгел, бәлки авылда һәм шәһәрдә капиталистик элементларны тулысынча җиңү һәм бетерү.

Ул вакытта большевиклар партиясенең авылдагы политикасының һәм тактикасының иң әһәмиятле мәсьәләсе авылдагы капиталистик элементларга **ничек** һөҗүм итү, һөҗүм бурычын нинди методлар белән һәм нинди формаларда хәл итү мәсьәләсеннән гыйбарәт иде. Иптәш Молотов, бу мәсьәләгә тулы анализ ясап, һәр төрле хыяли планнардан, алар бик яхшы булсалар да, сак булырга кушты һәм куелган сорауга конкрет һәм практик җаваплар бирүне таләп итте. Иптәш Молотов болай диде:

„Индивидуаль хуҗалыктан эре хуҗалыкка бер нинди дә җиңелчә сикерүләр турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Эш бары тик эре коллектив хуҗалыкларны эзлекле рәвештә үстерү юлы белән генә барырга мөмкин. Шундый юл гына дөрес юл. Эре хуҗалыкка күчкән вакытта крестьянга карата без һичбер төрле фантазияләргә, бер нинди дә ирексезләүгә юл куя алмыйбыз. Ләкин бу күчү хәзер инде авылның социаль-экономик үсешенең барлык якларыннан ыргылып чыга“. (ВКП(б) ның XV нче съездының стенография отчеты, 1081 нче бит).

Бу эштә культура гаят зур роль уйный. Революциядә культураның роле мәсьәләсендә социализм дошманнарының марксизмга каршы булган аңлатуларын фаш итеп, иптәш Молотов, эре коллектив хуҗалыкка күчү мөмкинлегенең үзен культурасызлыкны җиңүгә бәйле итеп кую мәгънәсезлек, меньшевизм, буржуаз идеология булган булыр иде, дип һәр вакыт күрсәтеп килә.

„Безнең культуралы булуыбыз авылның массовый күләмдә кооперативлашуы нигезендә аны экономик үзгәртеп кору белән бергә, идарә органнарының эшен яхшырту белән бергә, массаны бу эшкә тарту белән бергә күтәреләчәк. Культура һәм идарә итә белү, аларны киң массага карата алганда, бер-берсе белән бик нык бәйләнгәннәр“ (шунда ук, 1082 нче бит).

Совет экономикасының үсүе һәм шуның нигезендә культураның үсүе, СССР да халыклар массасының материаль хәле үсү беренче һәм икенче бишьеллыклар уңышларының турыдан-туры нәтиҗәләре булдылар. Бу бишьеллыкларны тормышка ашыруда В. М. Молотов күп һәм гүзәл хезмәтләр күрсәтте.

* * *

Партиябезнең күренекле теоретигы булып, марксизм философиясе методын бик яхшы үзләштереп, экономиканы тирәнтен белеп, СССР халыклары һәм беренче чиратта бөек рус халкы культурасының бөтен төзелешен, бөтен тарихын, барлык үзенчәлекләрен аңлап,—иптәш Молотов үзенең бөтен теоретик һәм практик дәүләт эшендә социалистик төзелешнең зур һәм катлаулы бурычларын чын-чыннан Маркcча, Ленинчә—Сталинча куя һәм хәл итә белү үрнәген бирә.

Лениннең турылыклы шәкерте, иптәш Сталинның иң якын көрәштәше сыйфатында В. М. Молотов, мәсьәләнең үзегенә тирәнтен кереп, аның йомшак якларын ачып, аның сыйфатына һәм әһәмиятенә, аның практик һәм принципиаль кыйммәтенә ялгышусыз бәя биреп, дәүләтнең һәрбер чарасына һәр вакыт марксизм-ленинизм принциплары ноктасыннан карый.

Теоретик принципиальлыкны дәүләт эшендәге практик акыллылык белән тирәнтен бергә кушып алып бару—Ленин—Сталин типындагы политик эшлекленең иң ачык үзенчәлекләреннән берсе. В. М. Молотов әнә шундый политик дәүләт эшлеклесе.

Үзенең күп яклы бөтен эше белән В. М. Молотов Совет дәүләт аппаратының ныгуына һәм яхшыруына гаят зур йогынты ясый.

Социалистик төзелеш бурычларына, халык хуҗалыгын планлаштыру, дәүләт аппаратын оештыру һәм аның эше мәсьәләләренә багышланган күп кенә речьләрендә иптәш Молотов, Лениннең һәм Сталинның дәүләт турындагы тәгълиматы буенча барып, социалистик җәмгыять төзүдә хәл иткеч көч булган Совет дәүләтенең ролен һәм әһәмиятен һәр вакыт аеруча күрсәтә.

Икенче бишьеллык бурычлары турында сөйләп, иптәш Молотов җәмгыятьнең үсеше турындагы марксистик теорияне бозган оппортунистларның схематизмын һәм мәгънәсез бәхәсләшүдән торган фикерләрен фаш итте, социалистик дәүләтнең кирәксезлеге яки үлеп баруы турында лыгырдауның тупас ялгыш һәм, зарарлы булуын күрсәтте. Иптәш Молотов сыйнфи көрәш фактларына Ленинчә—Сталинча карарга өйрәтә.

* * *

Иптәш Молотов Совет дәүләт аппаратын ныгыту турындагы мәсьәләне дә пролетар дәүләтнең әһәмияте турындагы, аның куәтен көчәйтү кирәклек турындагы мәсьәлә белән бергә бәйли. Үзенең теоретик әсәрләрендә, докладларында һәм речьләрендә, шулай ук Совет хөкүмәте башлыгы сыйфатында үзенең бөтен практик эшендә иптәш Молотов бу мәсьәләгә гаят зур әһәмият бирә.

Бюрократизмга каршы көрәш, аппаратның дөрес эшләве өчен, хөкүмәт карарларын төгәл һәм вактында үтәү өчен, үтәлүне системалы рәвештә тикшерү өчен, җанлы практик эш өчен көрәш—Совет хөкүмәтенең җитәкчесе сыйфатында В. М. Молотовның карашлары мәйданында менә шулар тора.

Иптәш Молотов аппаратны большевикларча, советча эшләргә, искелеккә катып калуны, бюрократизмны, формализмны, чиновникларча җавапсызлыкны тамырыннан йолкып ташларга өйрәтә.

„Работникларыбыздан, бигрәк тә, коммунистлардан без таләп итәргә тиеш булган минимум,—ул, эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар белән, крестьяннар һәм крестьян хатын-кызлары белән, колхозчылар һәм ялгыз хуҗалыкчылар белән сөйләшә белү һәм, бигрәк тә, алар сөйләгәнне, эшчеләр сөйләгәнне, эшче хатын-кызлар сөйләгәнне, крестьяннар сөйләгәнне, крестьян хатын-кызлары сөйләгәнне, хезмәткәрләр һәм түбәнге работниклар сөйләгәнне тыңлый белү... Әгәр дә работникларыбызның бөтен массасы бу яктан алга таба бер генә булса да күренерлек адым атласа, ул вакытта бюрократизмга каршы көрәш эшендә без зур гына уңышка ирешкән булырбыз. Ә моннан безнең төзелеш өчен зур файда булачак“. (В. Молотов „Социализм өчен көрәштә“, 422 нче бит).

Халык белән сөйләшә белү, халык сөйләгәнне тыңлый белү һәм монардан Совет власте өчен файдалана белү—Совет хөкүмәте башлыгы тарафыннан совет аппараты работникларына куелган төп таләп.

Үзенең җитәкче көче эшчеләр сыйнфы булган пролетар дәүләтебездә дәүләт аппаратының эш сыйфаты, аның эшенең чын социалистик методлары гаят зур әһәмияткә ия булуы турында иптәш Молотовның сүзләре бик тирән мәгънәле сүзләр.

„Безнең партиябез барлык колхозларны большевистик колхозларга әйләндерү, эшчеләр шикелле үк, хезмәт иясе крестьяннарның бөтен массасын яңа, сыйныфсыз җәмгыятьне актив төзүчеләргә әверелдерү бурычын бары тик пролетар диктатураның бөтен аппаратына таянганда гына һәм массаны социалистик яңадан тәрбияләү буенча эшне тагын да җәелдергәндә генә намус белән үтәячәк.

Шуның белән бергә, безнең партиябез кулында пролетариат диктатурасы эшчеләрнең үзләрен оештыруда һәм яңадан тәрбияләүдә куәтле аппарат булып тора“. (В. Молотов. „Социализм өчен көрәштә“, 545 нче бит, 1935).

Эшчеләрнең һәм крестьяннарның социалистик аңы, социалистик культурасы гаят дәрәҗәдә үсү халык арасыннан Сталин эпохасының гүзәл геройларын күтәргән стахановчылык хәрәкәтенең үсүендә күренде. Стахановчыларның Беренче Бөтенсоюз киңәшмәсендә иптәш Молотов:—бу кешеләр җаны һәм тәне белән эшчеләр массасы кешеләре, алар эшчеләр сыйнфындагы күпчелек, ләкин алар аерым сыйфатлы кешеләр,—диде.

„Аларның төп сыйфаты шунда ки, алар безнең хезмәт фронтыбызда югары аңлы көрәшчеләр, алар хезмәтне сөюче, үзләренең социалистик Ватаннарына чын күңелдән бирелгән кешеләр, буржуазияне бәреп төшергән эшчеләр сыйнфының чын уллары. Үз эшләренең иске нормаларын кыюлык белән җимергән һәм хезмәтне тагын да югарырак дәрәҗәдә яңача оештыруда җиңүчеләр булып чыккан бу кешеләр, яңа тормыш өчен, капиталистик коллыктан азат ителгән хезмәтнең тулысынча җиңүе өчен чын көрәшчеләр сыйфаты белән үсеп чыктылар“. (В. Молотов. Мәкаләләр һәм речьләр, 103 нче бит).

Бу гүзәл сүзләрдә стахановчыларның гына түгел, бәлки эшчеләр сыйнфы тарафыннан инде ирешелгән югары гомуми һәм техник культура нигезендә генә мөмкин булып әверелгән бөтен стахановчылык хәрәкәтенең үзенчәлекләренә тулы характеристика бирелгән.

Партиянең һәм дәүләтнең алтын фонды булган кадрларның әһәмияте турында партия һәм иптәш Сталин күрсәтмәләре буенча барып, иптәш Молотов юлбашчыбызның күрсәтмәләрен ничек итеп тормышка ашырырга, ничек итеп практикада үткәрергә кирәклеккә өйрәтә. Иптәш Молотов кадрларны сайлап алу, эшне чын-чыннан тикшерүне кую, хуҗалык һәм техник җитәкчелекнең сыйфатын күтәрү халык комиссарларының, совет учреждениеләре һәм предприятиеләре җитәкчеләренең иң зур бурычларыннан берсе булуына аларның игътибарын өзлексез юнәлдерә.

* * *

Халык хуҗалыгы үсешенең өченче бишьеллык планы турында партиянең XVIII нче съездында ясаган докладында иптәш Молотов Сталинчыл беренче ике бишьеллыкның уңышларына тулы характеристика бирде һәм өченче бишьеллыкның гаят зур перспективаларын күрсәтте.

Бу докладында иптәш Молотов хезмәт ияләренең материаль-культура дәрәҗәләренең үсүе мәсьәләсенә аеруча тукталды, моның халык хуҗалыгының гомуми уңышлары белән бәйләнгән булуын күрсәтте. Шуның белән бергә иптәш Молотов эшчеләрнең һәм крестьяннарның күпчелеген ияртеп баручы алдынгы кешеләрнең, социализмны батыр һәм актив төзүчеләрнең бу уңышлардагы рольләрен күрсәтте.

Хезмәт дисциплинасы, дәүләт дисциплинасы,—дәүләткә намус белән карау, үз бурычларына, үз йөкләмәләренә социалистик караш рухында тәрбияли торган дисциплина хезмәтне дөрес оештыруга, эш культурасына бәйләнгән.

Гомумән һәм аерым алганда планлаштыру өлкәсендә үтәлүне тикшерүнең нинди зур әһәмияте барлыкны В. М. Молотов берничә тапкырлар күрсәтеп үтте.

Партиянең XVIII нче съездында иптәш Молотов болай диде:

„Планнар безгә хуҗалык эшебезнең ничек алып барылуын тикшерү өчен кирәк. Әгәр дә план үтәлешне тикшерү белән бәйләнмәгән икән, ул—кәгазьгә, буш нәрсәгә әйләнә“.

План—ул җанлы кешеләр, ди иптәш Сталин.

План—ул коммунизмның бөек идеясе белән рухландырылган кешеләрнең иҗади көрәш программасы, ди иптәш Молотов.

„Менә шуңа күрә дә безнең планыбыз, безнең большевистик планыбыз, безнең Сталинчыл планыбыз—бөек көч ул. План буенча эшләү—нәрсә эшләргә һәм нинди максат өчен эшләргә кирәклекне белү дигән сүз. Безнең илебездә планнар бер нәрсә белән дә алыштырылмаслык оештыру көченә әверелделәр. Шуңа күрә дә кабул ителгән планны үтәү СССР хезмәт ияләренең намус эшенә әверелде“ (В. Молотов).

Үз көчләренә ышанычын югалткан, колонияләрне яңадан бүлү өчен көрәшкә кереп баткан, яңа сугыш башлаган капитализм дөньясын иптәш Молотов партиянең XVIII нче съездында җимергеч тәнкыйть астына алды. Капитализм илләре үзләренең күршеләрен ничек итеп талау турында гына кайгырталар. Капиталистик дөньяга капма-каршы булып башка дөнья—шатлык белән яңа тормыш иҗад итүче социализм дөньясы тора. Яш, куәтле, тәмам таза һәм җимерелмәслек бердәм Совет хөкүмәте үсә һәм ныгый.

Экономик ярышта ике дөньяның кайсысы җиңеп чыгачагына шикләнергә мөмкинме?! Шик юк һәм булырга да мөмкин түгел—СССР җиңүче булып чыгар!

* * *

Совет фәне, совет культурасы, совет интеллигенциясе каршында В. М. Молотовның күрсәткән хезмәтләре чиксез зур.

Совет фәнен, сәнгатен һәм культурабызның башка тармакларын үстерү һәм ныгыту өчен иптәш Молотовның ни кадәр күп эшләгәнлеген һәм эшләвен бөтен ил белә. Югары мәктәп работникларының беренче киңәшмәсендә, СССР фәннәр Академиясе эшенә бәйләнгән мәсьәләләр буенча иптәш Молотовның чыгышы, милли республикалардагы колхозчыларның һәм колхозчы хатын-кызларның партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре белән булган киңәшмәләрендә сөйләгән речьләре СССР да культура төзелеше буенча бик кыйммәтле директиваларны эчләренә алалар.

* * *

Вячеслав Михайлович Молотов—СССР ның бөтен дәүләт төзелешендә, эчке политиканың да, тышкы политиканың да барлык чараларында Сталинның беренче ярдәмчесе.

СССР тормышының барлык күренекле вакыйгаләре: Сталинчыл бишьеллыкларны эшләү һәм тормышка ашыру да; Сталин Конституциясе проектын эшләү дә; СССР ның күп санлы милләтләренең үсүе һәм алга баруы да; социализм дошманнарын, уң-троцкичы кабахәт заговорчыларны фаш итү һәм тар-мар итү дә; СССР оборонасын ныгыту да; күп кенә чит ил дәүләтләре белән тынычлык договорлары һәм дуслык договорлары төзү дә; Ватаныбызга бөтен дөнья алдында дан китергән геройларыбызны, күренекле, гүзәл кешеләребезне тәрбияләү дә—В. М. Молотов исме белән бәйләнгәннәр.

Советларның VIII нче съездында иптәш Молотов болай диде:

„Үз эшенең техникасын, үзенең бөтен производствосын, чын яңа культураны үзләштерүче миллионнарча кешеләр югарыга күтәреләләр. Яшрен лазутчикларның һәм ике йөзлеләрнең җимергеч эшләре белән дә, авыр орудиеләрнең снарядлары белән дә бу күп миллионлы сафларны бәреп ега да һәм тарката да алмассың.

Яңа хезмәт геройлары, социалистик төзелешнең югары техника белән коралланган ударниклары, данлыклы стахановчыларыбыз һәм стахановкаларыбыз әлегәчә һич булмаган тизлек белән югары күтәреләләр. Эшчеләрнең һәм эшче хатын-кызларның, колхозчыларның һәм колхозчы хатын-кызларның, культура, техника, фән һәм сәнгать кешеләренең торган саен яңа исемнәре безнең бөтен илебезгә билгеле була баралар һәм шундый һәрбер исем яңадан-яңа кешеләрнең килеп чыгуына сигнал булып хезмәт итә.

Безнең күз алдыбызда сафлары үсә торган һава, диңгез һәм Арктика геройларында, стихиягә каршы көрәшүче геройларда без, СССР ның теләсә нинди дошманнарына каршы көрәшүче геройлар образының гәүдәләнүен күрәбез.

Безнең белән шаяру начар икәнен дошман белеп торсын өчен, без тиешле булган бөтен нәрсә белән чын-чыннан коралланырга тиешбез“. (В. Молотов. Мәкаләләр һәм речьләр, 268—269 нчы битләр).

Иптәш Молотовның бу сүзләрен тормыш тулысынча расланы. Совет халкы бөек Ленин—Сталин байрагы астында бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган бөек җиңүләргә ирешә һәм ирешә.

ВКП(б) ның совет халкы белән аерылмаслык элемтәсен иптәш Молотов тәэсирләндерерлек ачык сүзләр белән гәүдәләндерде:

„Коммунистлар партиясенең һәм Совет властеның дошманнарын халык дошманнары дип исәпләү бездә гадәт булып әверелде...

Бу—безнең илебездә халыкның элекке вакытта булмаган эчке **мораль һәм политик бердәмлеге,** социалистик җәмгыятьнең мораль һәм политик бердәмлеге туганлыкны күрсәтә.

Халыкның мондый бердәмлеген бер генә капиталистик ил дә белмәде һәм белми...

Безнең илебездә халыкның мораль-политик бердәмлегенең җанлы гәүдәләнеше дә бар. Бездә социализм җиңүләренең символы булып әверелгән исем бар. Шуның белән бергә, бу исем совет халкының мораль һәм политик бердәмлегенең символы. Сез беләсез, бу исем—Сталин!“.

Бездә яңадан-яңа хезмәт һәм көрәшнең миллионнарча геройлары үсәләр. Аларны Сталинның даһилыгы тәрбияләде, аларны, аның көрәштәшләре тәрбияләде. СССР ның зур дәүләт эшлеклесе, Совет хөкүмәте башлыгы—Вячеслав Михайлович Молотов бу көрәштәшләр арасында мактаулы урын алып тора.

*) Кыскартып алынды.

ВЯЧЕСЛАВ МИХАЙЛОВИЧ МОЛОТОВ КАЗАНДА

Нолимдагы өч классны училищене тәмам иткәннән соң, Вячеслав Михайлович 1902 нче елны Казанга килә һәм беренче Казан реальный училищесенә укырга керә. Ул Георгиевский (хәзерге Свердлов) урамындагы 11 нче йортта, музыка училищесендә укучы туганнары белән бергә кечерәк кенә бер бүлмәдә тора. Вячеслав Михайлович үзе дә скрипкада яхшы гына уйный. Реальный училищедә Вячеслав Михайлович беренче укучы булып бара. Ул барлык фәннәр буенча отлично билгесе ала һәм беренче класстан икенче класска күчкәндә, отличного укуы өчен, педагогия советы карары буенча мактау грамотасы белән бүләкләнә.

1902—1904 нче елгы бөтен илне чолгап алган гомуми революцион күтәрелеш нәтиҗәсендә Казандагы студентлар арасында революцион оешмалар үсә. Вячеслав Михайлович революцион яшьләр белән аралаша һәм өлкән яшьтән үк революцион хәрәкәткә катнаша башлый. 1905 нче елны ул, 15 яшендә вакытында, революцион түгәрәкләрдә һәм царизмга каршы демонстрацияләрдә актив катнаша. РСДРП ның Казан Комитеты тапшыруы буенча листовкалар һәм прокламацияләр тарата.

Россиянең революцион пролетар үзәкләре тәэсире нәтиҗәсендә һәм РСДРП ның Казан Комитеты җитәкчелегендә Казан эшчеләре бердәм рәвештә самодержавиегә каршы күтәреләләр. 20 нче январьда Алафузов заводы эшчеләре забастовка башлыйлар. Свешников заводы, Рам заводы эшчеләре һәм башкалар Алафузов заводы эшчеләренең забастовкасына кушылалар. Забастовкада 3 меңнән артык кеше катнаша. Күп кешеле митингларда РСДРП ның Казан Комитеты вәкилләре речьләр сөйлиләр, алар эшчеләрне күтәрелергә чакыралар. РСДРП ның Казан Комитеты рус һәм татар телендә листовкалар һәм прокламацияләр басу һәм тарату буенча гаять зур эшләр үткәрә. Воззваниеләрне һәм прокламацияләрне заводларда, фабрикаларда һәм мастерскойларда тараталар. Алар почта аркылы Казан губернасының иң ерак почмакларына кадәр барып җитәләр. Эшчеләр арасында прокламацияләр тарату кебек җаваплы эш Казан Комитеты тарафыннан В. М. Молотовка да тапшырыла. Ул яшрен типографияләрдә басылган прокламацияләрне гаять зур осталык белән эшчеләр арасында тарата.

Большевистик партия студентлар арасында зур эш алып барды. Ул елларда студентлар революцион хәрәкәтнең күтәрелеше йогынтысында яшәделәр. 1905—1907 нче елларда югары һәм урта уку



В. А. Тихомирнов (сулда) һәм В. М. Молотов 1909 нчы елда Казанда.

йортларының студентлары эшчеләр арасында революцион пропаганда һәм агитация алып бару эшендә зур роль уйныйлар. РСДРП ның Казан Комитеты, 1906 нчы елның көзендә, масса арасында эшне көчәйтү теләге белән урта уку йортларындагы революцион яшьләрдән торган бер союз төзи. Бу союз „Казан шәһәрендәге урта уку йортлары укучыларының революцион союзы" дип атала. Союзга, аның төзелү көненнән үк Вячеслав Михайлович Молотов (Скрябин) җитәкчелек итә.

Вячеслав Михайлович Молотов урта уку йортларында күп кенә яшрен түгәрәкләр төзи. Мондый түгәрәкләр Казан урта механика (промышленность) училищесендә, беренче һәм өченче Казан хатын-кызлар гимназияләрендә, укытучылар („инородецлар") семинариясендә, беренче ирләр гимназиясендә һәм башка уку йортларында оештырыла. Жандарм полковнигы губернаторга болай дип хәбәр итә: „Урта уку йортларында тәрбияләнүчеләр арасында революцион идеялар таратыла, бу идеяләрне таратучылар — Казан реальный училищесенең тәрбияләнүчеләре, аңа тәрбияләнүче Скрябин аеруча энергия күрсәтә һәм яшрен эштә тора, шушы белән бергә ул РСДРП программасы буенча эшли" (партархив, фонд №36, дело №113). Бу вакытта Вячеслав Михайлович шулай ук эшендә Казан укытучылар („инородецлар") семинариясендә төзелгән түгәрәккә аеруча зур игтибар бирә. Бу семинариядә, башлыча, Казан губернасында яшәүче төрле милләтләрнең балалары (татарлар, чувашлар, марилар һ. б.) укыйлар иде.

Патша хөкүмәте тарафыннан азчылык милләтләр арасында таратылган милли дошманлыкны бетерү, халыкларны милли изүдән һәм хокуксызлыктан азат итү өчен көрәштә большевистик пролетариатка азчылык милләт теләгәнә күчергүнең һәм аларны изелгән милләтләр массалары арасында таратуның бик зур әһәмияте була һәм ул азчылык милләт халыклары арасында интернационализмны үсүенә ярдәм итә.

1906 нчы елның 7 нче мартында, җыелышларда катнашкан өчен студентларны семинариядән чыгаралар. Вячеслав Михайлович семинариядән чыгарылган студентларны яклап чыгыш ясый. Революцион Союзы директорга протест белдерү өчен студентларны оештыра. 100 кеше тарафыннан кул куелган протестта чыгарылган студентларны семинариягә яңадан алмыйча торып занятиегә керешмәячәкләре турында белдерелә.

1906 нчы елның сентябрендә 2 нче ирләр гимназиясендә укучыларның чуалышлары була. Укучыларның Революцион Союзы һәм аның җитәкчеләре В. М. Молотов һәм Виктор Тихомирнов чакыруы буенча беренче Казан реальный училищесе студентлары һәм башка студентлар укуны ташлыйлар, классларда парталарны дан һәм өстәлләрдән баррикадалар ясап 2 нче гимназияне яклап речьләр сөйлиләр һәм революцион җырлар җырлыйлар. Моның өчен күп кенә студентлар училищедән чыгарыла. Вячеслав Михайловичны һәм кайбер башка студентларны жандармия һәм мәктәп администрациясе күзәтү астына ала. Шуның белән бергә администрация өлкән класс укучыларының кече классларда укучылар белән аралашуларын тыю турында бойрык чыгара. Класс наздирательләренә студентларның квартираларында әледән-әле булырга, тәнәфес вакытында тәмәке тарту бүлмәсендә дежур торырга кушыла. Ләкин шундый репрессия булуга да карамастан, укучыларның революцион союзы РСДРП ның Казан Комитеты җитәкчелегендә үзенең эшен дәвам иттерә.

Реакция елларында Казандагы большевистик оешма чиктән тыш авыр шартларда эшли. Аның членнары бер-бер артлы кулга алыналар. В. Тихомирнов һәм В. Молотов партия оешмаларын яңадан аякка бастыру һәм аларны киңәйтү буенча ныклап эшкә керешәләр, яшьләр арасында эшлиләр. Алар яшьләрне үзләре тирәсенә туплыйлар, ленинизм идеяләре белән тәрбиялиләр. Үзләре дә төннәр буена революцион әдәбиятны өйрәнү өстендә утыралар.

РСДРП ның Казан оешмасы большевиклары реакция елларында эсерларга һәм меньшевикларга каршы килешмәүчән көрәш алып баралар, масса алдында аларның йөзләрен фаш итәләр. Меньшевикләр үзләренең карашларын яшь укучылар арасында да җимергеч отпорга очрыйлар.

Бер диспут вакытында Маркс—Энгельс—Ленин тәглиматына таянып, Вячеслав Михайлович Молотов аеруча тәрле һәм кискен чыгыш ясый. Ул меньшевикларның һәм эсерларның теориясен һәм тактикасын фаш итә. Меньшевиклар һәм эсерлар бер-бер артлы җиңелүгә дучар булалар һәм массада үзләренең йогынтыларын торган саен югалта баралар.

Вячеслав Михайлович каникул вакытларын Нолин шәһәрендә үткәрә һәм анда кайту белән үк партиянең урындагы оешмасы белән элемтә урнаштыра һәм партоешма заданиесе буенча эшли. Жандарм идарәсе 1907 нче елны Казан губернаторына биргән хәбәрендә болай дип яза: „Беренче Казан реальный училищесенең укучысы В. Скрябин һәр елны җәйге каникул вактында Нолин шәһәрендә социал-демократия оешмасының эшендә актив катнаша" (фонд №36, дело №113). Вячеслав Михайлович артыннан жандарм идарәсенең күзәтүе тагын да көчәйтелә.

1909 нчы елның 29 нчы январенда казандагы социал-демократик комитетның бөтен составы диярлек тар-мар ителә. Ләкин партия эше туктатылмый. Иркендә калган В. М. Молотов һәм В. А. Тихомирнов оешманың эшен яңа баштан кору буенча эшли башлыйлар.

„Дядя" (В. М. Молотовның партиядәге беренче кушаматы) партиянең Казан оешмасының турыдан-туры җитәкчесе булып әверелә. Вячеслав Михайлович РСДРП комитетын кыска гына вакыт эчендә аякка бастыра һәм аның эшен киң җәелдерүне тәэмин итә. Бу жандарм идарәсе өчен көтелмәгән хәл була. Жандарм идарәсе 29 нчы январьдагы „чистартудан" соң бөтенләй „тынычланган" иде. РСДРП ның Казан Комитеты имзасы белән барлык уку йортларында һәм шәһәрдә прокламацияләр күренә башлый. Комитет бу вакыт эчендә „Крестьяннарга", „Казан шәһәрендәге укучы яшьләргә", „Гимназистларга" дигән прокламацияләр чыгара. „Наша жизнь" газетасын басуны оештыру эшләре алып барыла, ләкин газетаны чыгару мөмкин булмый. Газетаны басу өчен хәзерләнгән гектограф В. Тихомирновны кулга алган вакытта полиция кулына эләгә. Полиция Тихомирновны кулга алырга килгәндә гектографта прокламация язылган була. Прокламацияне полиция кулына бирмәс өчен Виктор Тихомирнов гектограф өстенә утыра һәм шулай итеп прокламацияне юкка чыгара.

Вячеслав Михайлович Казан шәһәрендә эшләү белән генә чикләнеп калмый. Ул Пензадагы, Самарадагы, Алабугадагы һәм күп кенә башка шәһәрләрдәге партоешмалар белән элемтә урнаштыра.

Вячеслав Михайлович җитәкчелек итә башлаганнан соң партия оешмасында ныклы тәртип урнаштырыла. Комитетның членнары арасында эшләр бүленә, оешманың архивына мөдир, комитет ихтыяҗлары өчен һәм политик тоткыннарны тәэмин итү өчен акча җыю буенча җаваплы кешеләр билгеләнә. Акча җыю өчен лотерейлар оештырыла. Җыелган акчаның бер өлеше эшсезләр семьяләренә таратыла һәм бер өлеше комитет ихтыяҗларына тотыла. Партия оешмасының үзенең яшрен китапханәсе була. Ул Виктор Тихомирновның ата-аналары тора торган йортның бакчасындагы, куе сирен агачлары белән капланган беседкада саклана. Кыш көннәрендә китапханә башка урынга күчерелә. Аңа Тихомирнов җитәкчелек итә. Тихомирновны кулга алган вакытта табылган китапларның исемлеге жандарм идарәсе делоларында салынган. Исемлектә күрсәтелгән китаплар һәм брошюралар арасында РСДРП программасы, РСДРП ның IV нче берләштерелгән съездының карарлары һәм резолюцияләре, „Югары типтагы түгәрәк программасы" дигән брошюра, „Пролетарий" газетасының берничә номеры, РСДРП ның Казан Комитеты органы „Рабочий" газетасының беренче номеры һәм башкалар булган. Китапханәдә 193 исемдә төрле китаплар һәм брошюралар сакланган.

Югары, урта һәм түбәнге тип түгәрәкләрдә эш киң җәелдерелә. Алар һәр көнне төрле урыннарда занятиеләр үткәрәләр.

Эшче һәм укучы яшьләргә Вячеслав Михайловичның йогынтысы гаять зур була.

1909 нчы елның мартында Борисов дигән полицейскийга реальный училище студенты Вячеслав Михайлович квартирасы артыннан күзәтү урнаштыру тапшырыла. Борисов тырышып эшли башлый. Ул Вячеслав Скрябин квартирасында булучыларның барсын да заметкага ала. Вячеслав Михайловичның квартирадан китү һәм кайту вакытларын һәр көнне язып бара һәм бу маглүматларны берләп жандарм идарәсенә тапшыра. 1909 нчы елның 22 нче мартында партиянең Казан оешмасы тар-мар ителә, барлыгы 16 кеше кулга алына.

Жандарм идарәсе делоларында Вячеслав Скрябинны кулга алу өчен бирелгән ордер сакланган. Ордерда болай дип язылган: „1909 нчы ел, 21 нче март. Казан жандарм идарәсе начальнигы, 1881 нче елның 14 нче августында патша хөкүмәте тарафыннан расланган дәүләт сакчылыгы турындагы положение нигезендә, Казан шәһәренең 4 нче часть приставына, беренче Казан реальный училищесе укучысын— Гиоргиевский урамында Лихачев йортында торучы Вячеслав Скрябинда тентү ясауны тапшыра. Тентү ясалучы кулга алынырга тиеш түгел, тентү вактында барлык яшрен язышуларны күздә тотарга" (фонд № 36, дело № 113).



Вячеслав Михайлович Молотов Казанда. РӘСЕМДӘ: Казан Педагогия училищесе (элекке 1 нче шәһәр реальный училище) бинасы. Иптәш Молотов Казанда шушы реальный училищедә укыган.

Тентү вактында Вячеслав Михайловичта комитет ихтыяҗларына акча җыю өчен хәзерләнгән „РСДРП ның Казан Комитеты" дигән ике данә талоннар кенәгәсе, комитетның отчетлары, Алабугадагы укучылар группасы белән язышкан хатлар һәм башкалар табыла. Тентү нәтиҗәсе нигезендә жандарм идарәсе губернаторга болай дип хәбәр итә: „Вячеслав Михайлович „Дядя" кушаматы астында төп җитәкчеләрдән берсе, ул укучылар оешмасына гына түгел, бәлки 1909 нчы елның январенда комитет членнарын кулга алганнан соң, РСДРП ның Казан Комитетына да җитәкчелек иткән. Агентура маглүматларына караганда, ул 1906 нчы елны ук инде социал-демократик оешмага кергән. Шуңа күрә дә Скрябиннән опись буенча алынган материалларның күплегенә һәм җиддилегенә караганда, аны иркендә калдырырга һич тә ярамый" (фонд № 36, дело № 113).

26 нчы мартка каршы төндә В. М. Молотов (Скрябин) кулга алына һәм Казан губерна төрмәсенә утыртыла. Ул анда 3 ай утыра. Бу аның беренче тапкыр кулга алынуы була. Вячеслав Михайлович төрмәдә утырган вактын марксистик-ленинчел әдәбиятны җентекләп өйрәнүгә һәм алдагы көрәш өчен революцион теория белән коралланугa файдалана. Моның өчен ул полиция тарафыннан алынган китапларын һәм дәфтәрләрен төрмәгә китерүне сорый. Озак язышканнан соң аңа үзенең 15 дәфтәрен һәм 6 китабын бирәләр. 1909 нчы елның 20 нче июнендә полиция департаменты 82610 нчы номерлы бойрык чыгара. Бу бойрыкта: „Нолин шәһәре мещане—Вячеслав Скрябин полиция күзәтүе астында ике елга Вологда губернасына җибәрелә" диелә.

А. И. Лебедева.

Татпартархивның фәнни сотруднигы.

Вячеслав Михайлович Молотов Казанда. РӘСЕМДӘ: Свердлов урамындагы 11 нче номерлы йорт ишек алдындагы флигель. Иптәш В. М. Молотов 1902 нче елда шушы йортның 2 нче катында торган.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ ЯКЫН КӨРӘШТӘШЕ

1926 — 1929 нчы елларда миңа иптәш Вячеслав Михайлович Молотов белән берничә тапкыр очрашырга, татар һәм башкырт халыклары арасында эшләү мәсьәләләре буенча сөйләшергә туры килде. Сөйләшүләрдә иптәш Молотов һәр вакыт бик гади һәм саф күңелле иде, безне, милли республикалардан килгән работникларны зур игтибар белән тыңлады, киңәшләр һәм күрсәтмәләр бирде.

1927 нче елның ахрындамы, яки 1928 нче елның башындамы, төгәл хәтерләмим, ВКП(б) Үзәк Комитеты утырышларының берсендә милли республикалардагы вакытлы матбугат турындагы мәсьәлә тикшерелде. В. М. Молотов милли матбугат эшен яхшы итеп оештыруны яклап сөйләде. Ул милли республикалардагы вакытлы матбугатны, шул исәптән татар матбугатын киметмәүне, бәлки, киресенчә, аның эшен тагын да киңрәк җәелдерүне яклады.

Матбугат эшенә бәйләнешле булган тагын бер очрашуны хәтерлим. Сүз татар телендәге вакытлы матбугат турында бара иде. Иптәш Молотов ул вакытта милли матбугат өчен аеруча тар булган мәсьәләгә гадәттәгечә бик сизгер һәм игтибарлы төстә якын килде һәм аны конкрет төстә хәл итәргә ярдәм итте.

Иптәш Молотовның үзенең көндәлек эшендә иге-чиге булмаган социалистик Ватаныбызда яшәүче халыкларның ихтыяҗларына һәм сорауларына гаять зур игтибар бирүен, Ленин—Сталин милли политикасын аның армый-талмый һәм эзлекле рәвештә тормышка ашыруын күрсәтә торган күп кенә башка мисалларны да китерергә мөмкин булыр иде.

Соңыннан, 1938—39 нчы елларда мин СССР Верховный Советы Сессияләрендә һәм аның Президиум утырышларында В. М. Молотов белән берничә тапкыр очраштым. Һәр вакыт, аның белән сөйләшергә туры килгәндә, иптәш Молотов безнең Татарстан республикасының тормышы турында: Татарстанда промышленностьның, авыл хуҗалыгының һәм культураның үсеше турында сораша иде. Бер вакытны мин иптәш Молотовта кабул итүдә булдым. Беседада ул безнең республикада кешеләрне, бигрәк тә милли кадрларны сайлап алу һәм үстерү мәсьәләләрен, юл төзелеше мәсьәләләрен куйды. Иптәш Молотов, яхшы юллар төзүнең җидди эш икәнлеген, культураның ачык күрсәткечләренең берсе икәнлеген һәм хезмәт ияләренең көнкүреш хәле үсүгә, республиканың экономикасы үсүгә аның ярдәм итүен күрсәтеп үтте.

Иптәш Молотов безнең орденлы Татарстан республикасы турында, аның чәчәк атуы турында һәр вакыт кайгырта, татар халкының тормышы белән һәр вакыт кызыксына. Иптәш Молотов Татарстан АССР ның бөтен халык хуҗалыгының кызу рәвештә күтәрелүе өчен күп нәрсәләр эшләде.

Мин В. М. Молотовның докладларын күп тапкырлар тыңладым— ВКП(б) ның XVIII нче съездында, Сессияләрдә тыңладым, аннан элек тә тыңлаганым бар иде. Һәр вакыт тирән эчтәлекле һәм марксизм-ленинизм фәнен яхшы белү белән сугарылган бу докладлар тыңлаучыларның игтибарын үзенә тарталар, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның бөек идеяләрен тормышка ашыру өчен, коммунизмның җиңүе өчен алдагы көрәшкә энтузиазмны һәм энергияне күтәрәләр.

Г. А. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 6 март. Рәсми белдерүләргә караганда, Германия отряды көчле артиллерия хәзерләгеннән соң Мажино линиясендә дошманның бер постына атака ясаган. „Сугыш кырында дошманның 20 гә якын кешесе үтерелгән. Англиянең 1 фельдфебеле һәм 15 солдаты пленгә алынган".

БЕРЛИН, 7 март. Германия армиясе верховный командованиесенең бүгенге сводкасында, 6 нчы мартка каршы төндә Англия самолетлары Германиянең төньяк-көнбатыш ярларына якынлаштылар, дип күрсәтелә. Англиянең бер самолеты Зильд атауларыннан төньяктарак Дания территориясе аркылы очып чыккан.

ПАРИЖ, 7 март. Рәсми белдерүдә хәбәр ителгәнчә, кичә фронтта „әһәмиятле бер нәрсә дә булмаган. Төнлә белән Мозельдән көнчыгыштарак дошманның һөҗүме кире кагылган".

БРЮССЕЛЬ, 7 март. Франциядә чыга торган „Журналь" газетасының бүгенге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Мозельдән көнчыгышта немецлар белән Англиянең экспедицион корпусының алгы постлары арасында беренче тапкыр бәрелеш булган. Англичаннар нык каршылык күрсәткәннәр. Ике кеше үтерелгән, берничә кеше яралаган һәм берничә кеше пленгә алынган. Немецларның бер кешесе үтерелгән.

Вогездан көнбатыштарак немецларнең берничә патруле үтеп керергә маташып караган, ләкин безнең разведчикларыбыз тарафыннан кире алып ташланылган".

ЛОНДОН, 6 март. Диңгез министрлегенең хәбәр итүенә караганда, конвой системасы кертелгәннән бирле Англия сугыш кораблары тарафыннан 10.782 пароход күзәтү астында алып барылган, шул исәптән 1.075 пароход нейтраль илләрнеке булган.

Күрсәтүләргә караганда, моннан ике атна чамасы элек Германиянең 6 пароходы Виго портыннан (көнбатыш Африка) Германиягә кайтырга чыккан, ләкин алардан бары бер генә пароход кайтып җиткән. 3 пароход Англия кораблары тарафыннан кулга алынган, 4 нче пароход үз командасы тарафыннан батырылган, 5 нчесе Норвегия ярлары янында авариягә очраган.

ПАРИЖ, 6 март. Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Италиянең тагын ике пароходы Даунста (Англиянең көньяк-көнчыгышында) Англиянең диңгездәге контроль базасына китерелгән. Хәзер монда Италиянең күмер төягән 9 пароходы бар. Агентлыкның сүзләренә караганда, пароходларга төялгән күмер „Германия күмере" икән. (ТАСС).

Испаниядә крестьяннәр җирен алпавытларга кире кайтарып бирү

НЬЮ-ЙОРК, 7 март. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Мадридтан хәбәр итүенә караганда, Испания хөкүмәте алпавытлардан республика хөкүмәте тарафыннан алынып крестьяннәргә бирелгән җирләрне махсус декрет белән алпавытларга кире кайтарып бирә. Декрет нигезендә крестьяннәр алпавытларга тиешле компенсация түләгән шартларда бу җирдә арендаторлар сыйфатында кала алалар.

Сайто минсейто партиясеннән чыгарылды

ТОКИО, 7 март. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә иртә белән минсейто партиясе Сайтоны үз теләге буенча партия сафларыннан чыгару турында карар кабул иткән. Партиянең генеральный секретаре Уцигасаки Сакусабуроның әйтүенчә, Сайтоны партиядән чыгару турындагы карар „авыр хәлләр белән бәйләнгән", бу хәлләр „милли оешманы көчәйтүне" таләп итәләр.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

БҮГЕН ТЕАТР ҺӘМ КИНОЛАРДА

Татар Дәүләт Опера театры (ТДАТ бинасында)—Ирек. Талон 84.
Зур Драма театры—Ленин. Талон 119.
Дәүләт циркы—Золло тимер юлы һәм зур цирк уены.
„Электро—Седовчылар. „Унион"—Дуслар. „Кызыл Йолдыз"—Яшьләргә. „Пионер—Дүртенче перископ. „Чаткы"—Бәхетле финиш. „Колхозник"—Минин һәм Пожарский. „Рот-Фронт"—Укытучы. Культура сарае—Патриот.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 746 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 929.